**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Колгына авыл җирлегенең Дәвеш авылында 2019 елның 19 ноябрендә кабул ителгән 2 нче номерлы "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Колгына авыл җирлегенең Дәвеш авылында халык җыены нәтиҗәләре һәм 2020 елда үзара салым кертү турында” халык җыены карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Сез

Колгына авылында су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау (шул исәптән, су линияләрен ремонтлау, насос сатып алу), гидрантлар һәм башка материаллар сатып алу, шулай ук беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү максатларында эшләр һәм хезмәтләр күрсәтү;

Колгына авылының К. Маркс, Мәгариф һәм Ленин урамында вак таш җәеп автомобиль юлларын ремонтлау һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту;

Колгына авылы урамнарын яктырту (светодиод лампалар, чыгым материаллары сатып алу);

Колгына авылы зиратын коймалау;

Колгына авылында каты коммуналь калдыкларны җыю эшчәнлеген оештыру;

Колгына авылы территориясен төзекләндерүне оештыру;

эшләрен башкарып җирле мәсьәләләрне чишү максатында тоту өчен шушы җирлектә яшәүче балигъ булган, Колгына авылы территориясендә теркәлгән һәр кеше исәбеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентларны, бала вакытыннан инвалидларны, коляскалы инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, күп балалы гаиләләрне кертмичә) 2020 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендәге үзара салым кертү белән; килешәсезме?

«ӘЙЕ» «ЮК».

соравы буенча 19.11.2019 үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенгы беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 109 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 64.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 62 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче Дәвеш авыл җирлегенең Колгына авылында хылык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип таныргa.

2.« Сез

- Колгына авылында су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау (шул исәптән, су линияләрен ремонтлау, насос сатып алу), гидрантлар һәм башка материаллар сатып алу, шулай ук беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү максатларында эшләр һәм хезмәтләр күрсәтү;
- Колгына авылының К. Маркс, Мәгариф һәм Ленин урамында вак таш җәеп автомобиль юлларын ремонтлау һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту;
- Колгына авылы урамнарын яктырту (светодиод лампалар, чыгым материаллары сатып алу);
- Колгына авылы зиратын коймалау;
- Колгына авылында каты коммуналь калдыкларны җыю эшчәнлеген оештыру;
- колган авылы территориясен төзекләндерүне оештыру;

Белән килешәсезме?

соравы буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Колгына авылында су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау (шул исәптән, су линияләрен ремонтлау, насос сатып алу), гидрантлар һәм башка материаллар сатып алу, шулай ук беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү максатларында эшләр һәм хезмәтләр күрсәтү;

- Колгына авылының К. Маркс, Мәгариф һәм Ленин урамында вак таш җәелгән автомобиль юлларын ремонтлау һәм җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту;
- Колгына авылы урамнарын яктырту (светодиод лампалар, чыгым материаллары сатып алу);
- Колгына авылы зиратын коймалау;
- Колгына авылында каты коммуналь калдыкларны җыю эшчәнлеген оештыру;
- колган авылы территориясен төзекләндерүне оештыру;

эшләрен башкарып җирле мәсьәләләрне чишү максатында тоту өчен шушы җирлектә яшәүче балигъ булган, Колгына авылы территориясендә теркәлгән һәр кеше исәбеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентларны, бала вакытыннан инвалидларны, коляскалы инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, күп балалы гаиләләрне кертмичә) 2020 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендәге үзара салым кертергә.

4.Халык җыены нәтиҗәләрен информацион стендларда һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында игълан итәргә.

**Авыл җирлеге**
**Башлыгы** **Т.Т. Хөсәенов**